| | | |
|---|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛТАЧ РАЙОН<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__25__» ___05____ 2020 г. № _186_

**Балтач муниципаль районында аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вәзгыятьнең начараю шартларында Россия икътисадының аеруча зыян күргән тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм чаралары турында» 2020 елның 19 мартындагы 670-р номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсе, «Арендага алучыларны - кече һәм урта эшкуарлык субъектларын Татарстан Республикасы дәүләт казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче дәүләт мөлкәтен арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләүдән 2020 елның апрель-июнь айларында азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү турында» 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты күрсәтмәсе нигезендә Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) һәм дәүләт милке чикләнмәгән җирләрне (алга таба муниципаль мөлкәт) арендалау шартнамәләре буенча Балтач муниципаль районы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

а) кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, авиайөкташу, аэропорт эшчәнлеге, автойөкташу, мәдәният, ял оештыру һәм күңел ачу, физкультура - сәламәтләндерү эшчәнлеге һәм спорт, туризм өлкәсендә хезмәт күрсәтүләр, кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы, өстәмә белем бирү, дәүләтнеке булмаган белем бирү учреждениеләре, конференцияләр һәм күргәзмәләр оештыру буенча эшчәнлек, халыкка көнкүреш хезмәтләре күрсәтү (ремонт, юу, химчистка, чәчтарашханә һәм матурлык салоннары хезмәтләре) өлкәләрендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы арендага алучылар - кече һәм урта

эшкуарлык субъектлары мөрәҗәгатеннән соң 7 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының муниципаль казнасын (шул исәптән җир кишәрлекләрен) тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча мондый арендага алучыларны 2020 елның апрель-июнь айларында аренда түләүләрен түләүдән азат итүне күздә тоткан өстәмә килешүләр төзү. Әгәр аренда шартнамәсендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләре) күрсәтелгән эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен аннан файдалану максатларында һәм тиешле мөлкәттән күрсәтелгән төрне (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдалануны раслый торган документлар булганда, арендага бирү каралган булса, күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү гамәлгә ашырыла.

б) Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында арендага алучылар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен әлеге карар үз көченә кергән көннән өч эш көне эчендә әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә өстәмә килешүләр төзү мөмкинлеге турында мәгълүмат урнаштыру.

2. Әлеге карар нигезендә күрсәтелгән аренда түләүләрен түләүдән азат итү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага әлеге карарның 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы казнасын тәшкил итүче муниципаль мөлкәтне (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалау шартнамәләре буенча узган чорда аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмаган, кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән арендага алучылар - кече һәм урта эшкуарлык субъектлары карата гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасына 2020 елның II кварталыннан башлап хисап кварталыннан соң килүче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча әлеге карарның үтәлеше турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми http://www.baltasi.tatarstan.ru сайтында урнаштырырга һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://www.pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов